КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 30 декабрь г.Казань № 1769

«Минем субсидияләр» дәүләт мәгълүмат
системасы турында

Татарстан Республикасында мәгълүмат технологияләрен үстерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Минем субсидияләр» мәгълүмат системасын булдыру турында» 2020 ел, 2 ноябрь, 986 нчы карары белән булдырылган мәгълүмат системасын – «Минем субсидияләр» дәүләт мәгълүмат системасы итеп;

«Татарстан Республикасының Цифрлы трансформация үзәге» дәүләт казна учреждениесен – Системаның дәүләт заказчысы һәм операторы итеп;

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгын – мәгълүматка ия булучы итеп.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына 60 көн эчендә Система турындагы нигезләмә проектын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына билгеләнгән тәртиптә кертергә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Минем субсидияләр» мәгълүмат системасын булдыру турында» 2020 ел, 2 ноябрь, 986 нчы карарының 2 – 6 пунктлары үз көчен югалткан дип санарга.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин